*Әти-әниләр, сезнең өчен!*

# Балаларны татар халкының гореф-гадәтләре үрнәгендә тәрбияләү мөһим

**Туган тел!** Һәркем өчен газиз сүз бу. Чөнки тел – тормышчыганагы,белем чишмәсе. Тел ул зур бер гөлбакча кебек анда йөргәнсаен гөлләрнең төрлелегенә шаккатасың, хушисләрен тоясың, матурлыгына сокланасың.Тел кешеләргә бер-берсен аңларга, теләк-максатларын, уй-фикерләрен белергә ярдәм итә.

Бүгенге көндә балалар бакчасы тәрбиячеләре алдында торган бурычларның иң мөһиме – сабыйларга максатлы рәвештә – үз туган телен өйрәтү, шулай ук аларны халкыбызның сәнгате, гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, йолалары, милли әдәбияты белән таныштыру.

Татар халкының тарихы, гореф-гадәтләре, традицияләре, көнкүреш һәм тел үзенчәлекләре халык уеннарында киң чагылыш таба. Татар халкының уеннарын балалар бик тиз өйрәнәләр һәм бик теләп уйныйлар. Балаларга уен тәкъдим иткәндә, аларның иң яхшы үзләштерә торганнарын сайларга кирәк.

Без “Мәче һәм тычкан”, “Ябалак”, “Йоклаган песи”, “Очты ,очты...”, “Аю-бүре”, “Күрсәт әле, үскәнем” кебек татар халык уеннарын еш уйныйбыз. Уеннардан балалар уңай тәэсир алалар, шулай ук тел байлыгын арттыралар.

Сюжетлы-рольле уеннарга да бик зур урын бирелә. Бу балаларга бер-берсенә хөрмәт, әдәплелек хисен үстерергә ярдәм итә. Шулай ук дидактик уеннарга да зур урын бирелә. Бу уеннар “Нәрсә артык?”, “Парын тап”, “Кем баласы”, “Калфак бизәү, комзол бизәү” һ.б. баланың дөрес фикерләү, уйлап табусәләтен үстерә.

Уеннар, такмаклар, табышмаклар, санамышлараша ирештерсәк, безнең гореф-гадәтләр, йолалар, бәйрәмнәр онытылмас, гасырлардан-гасырларга күчеп дәвам итәр, мәнге сакланыр, милләтебез яшәр.

## «Балаларны музыкаль тәрбияләүдә татар халкының Җырлы – биюле уеннарының әһәмияте»

Балалар тормышында уеннарның әһәмиятен кем белми? Без инде “Сәламәт тәндә – сәламәт акыл”, - дибез. “Кеше ул йозе бедән дә, сүзе белән дә, җаны белән дә матур булырга тиешле”, - дибез. Ләкин ул тән – җан матурлыклары да кешегә үзлегеннән генә бирелмиләр. Сәламәтлекне дә, тышкы-эчке матурлыкны да яулап алырга, аның өчен көрәшергә кирәк. Моның өчен балага иң табигый һәм төп чара өч: эш һәм уку, аннан уен.

Халык уеннары балаларны үз инициативаларына ышанып тапшыра һәм аларда ирекле ярыш рухы, иҗади тапкырлык, үткенлек, өлгерлек, җегәрлек рухы кабыза.

Бигрәк тә җырлы-сүзле уеннарның бу юлда үзенсә әһәмиятләре зур. Җырлы-сүзле, димәк – авыз иҗаты катышкан уеннар. Күмәк җыр яки ритмик сүзләр уенда баланың хәрәкәтләрен көйгә сала, бала ул күмәкнең ритмын үзендә тоя һәм шул ритмда хәрәкәт итә башлый, шуның белән шәхес үзенең күмәккә мөнәсәбәтен билгели, җәмгыяттәге урынын таба. Җырлы-сүзле уеннар баланы музыкаль авазлар белән хисләндерәләр, аның күңелендәге нәфислек тыйгысы уяталар, аны музыкаль авазлар тоярга, күмәк һәм уртак хис белән хисләнергә өйрәтәләр, аның хәрәкәтләрен музыкаль ритмга, көйгә салалар, күңелен уяталар, дәртләндерәләр, уенын мәгъналәндерәләр һәм күңелендә  нәфислек тыйгысы уятып, аңа чиксез ләззәт бирәләр.

Димәк халык уеннарының баланы иҗтимагый көйгә, гармониягә салуы, аңа максатка ирешү юлында сугышчанлык рухы бирүе һәм көрәшкә ихтиярын чыныктыруы, ягъни тәнен дә, рухын да тәрбия итүе ягыннан әһәмиятләре гаять дәрәҗә зур.



# Музыка аша әхлаклылык һәм толерантлылык тәрбияләү.

Музыкаль тәрбия – педагогикада үсеп килүче буынны тәрбияләүнең аерылгысыз өлеше булып карала.

Музыкаль тәрбия – ул кешенең рухи ихтыяҗы, аның әхлакиаңы, фикерләү сәләте, эмоциональ фикер үсеше һәм тормыш күренешләрең эстетик бәясе формалашуы.

Музыкаль тәрбия – шулай ук кешенең музыкаль культурасын үстерә. Сәнгать хәрвакыт нәфис образларга таяна.Музыкаль сәнгатьнең специфик үзенчәлеге булып музыкаль образларда тормыш күренешләрен яктырту тора.

Музыка кечле эмоциональ йогынтыга ия. Ул кешедә яхшы хисләр уята. Аны өстенрәк, чистарак һәм яхшырак итә.

Балаларны музыкага өтәрүнең бер формасы булып музыка шөгыле тора.

Музыка шөгыле балаларның характеры формалашуга, үз-үзләрен тоту нормасын үтәүгә ярдәм итә. Музыка шөгыле – балаларның матур зәвыгын үстерүче күпкырлы танып белү процессы. Ул музыкаль сәнгатькә мәхәббәт тәрбияли. Шәхеснең әхлаки сыйфатларын һәм әйләнә-тирәгә эстетик мөнәсәбәтен формалаштыру.

